РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урамы, 21 йорт

тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.01.2021 №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл башкарма комитеты тарафыннан 2016 елның 15 декабрендә №45 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге №668/пр боерыгы белән расланган “Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 19 июнендәге 892/пр номерлы боерыгын кабул итү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл башкарма комитетының 15.12.2016 №45 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы нигезләмә” гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"СРс – Татарстан Республикасында икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданының 1 кв.метрына уртача бәя.»;

1.2. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Татарстан Республикасында икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданының 1 кв.метрының уртача бәясе федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең бердәм ведомствоара мәгълүмат-статистика системасында (ЕМИСС) ирекле файдалана алырлык мәгълүматлары буенча билгеләнә.

Татарстан Республикасы буенча әлеге мәгълүмат булмаган очракта, федераль округ буенча икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданының 1 кв.метрының уртача бәясе кулланыла, аңа Татарстан Республикасы керә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм авыл җирлегенең рәсми стендларында бастырып чыгарырга.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин